Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, “Зур Кукмара авылы гомуми урта белем бирү, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәбе”

# “Ризаэддин Фәхреддин мирасы һәм татар дөньясы”

**X-XI сыйныф укучылары өчен электив курс программасы**

Автор: татар теле һәм әдәбияты

укытучысы

Гаделшина Рузия Зөфәр кызы

2015 нче ел

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы, Зур Кукмара гомуми урта белем бирү, аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гаделшина Рузия Зөфәр кызының "Ризаэддин Фәхреддин мирасы һәм татар дөньясы" темасына язылган электив курс программасына бәяләмә**

Хезмәт әлеге темага язылган электив курс программасы аңлатма язуы, төп эчтәлек, йомгаклау, кулланылган әдәбият исемлегеннән тора.

Хезмәт авторы курсның кереш өлешендә максат һәм бурычлар, Р.Фәхреддиннең мәдәни һәм иҗтимагый тормышта тоткан урыны, тормыш юлы һәм иҗади мирасы чагылдырыла, бирелгән теманың әһәмияте һәм актуальлеге ачыла. Европа, Америка илләрендә яхшы мәгълүм булган акыл иясе мирасын барлау, кылган гамәлләрен һәм иҗатын өйрәнү, аларга объектив бәя бирү – электив курсның актуальлеген раслаучы бер дәлил. Биредә укучылар ия булырга тиешле белем һәм кунекмәләрдә дә эзлекле күрсәтелә.

Хезмәт күңелдә беренче карашка ук соклану хисләре уята. Хезмәт күләмле генә, техник таләпләргә җавап бирә. Ул үзенең композиция төзелеше буенча шактый катлаулы, шуңа да карамастан бүлегара бәйләнешләр ныклы, фикерләр эзлекле тезелеп бара. Хезмәт авторының мәсьәләне яктыртуга ныклы уйланулар аша килүе күренә.

Рузия Зөфәр кызы төзегән электив курсның "Р. Р.Фәхреддиннең тарихи эшчәнлеге" дип исемләнгән беренче бүлегендә татар халкының килеп чыгышына кагылышлы карашлар ачыклана, китапларындагы язмалар уку һәм анализлау өчен тәкъдим ителә.

Икенче бүлектә Р.Фәхреддиннең әдәби һәм тәнкыйди эшчәнлегенә урын бирелә. Проза жанрын үстерүдә тоткан урыны ачыклана. "Сәлимә, яки гыйффәт", "Әсма, яки гамәл вә җәза" әсәрләре аша хатын-кыз бәхете темасы үзәккә куела. Тәнкыйди эшчәнлегенә әһәмият бирелә. Бер яктан, хезмәт авторы бәхет төшенчәсен аңлауны электән килгән карашлар ноктасыннан ачыклый, икенчедән, аны чагылдыруның әдәбияттан килгән традицияләрен барлый һәм, шул исәптән, мәсьәләгә карата мөнәсәбәттә гендер (җенескә бәйле) аерымлыкларны да чагылдырып уза. Шунысы кызыклы: бәхетне аңлауда һәм әсәр эчтәлеге аша чагылдыруда гасыр башында ир-ат һәм хатын-кыз шагыйрәләр иҗатында аерымлыклар күзәтелми икән. Димәк, ир-атларыбыз гүзәл затларны борчыган проблемаларны тирән аңлаганнар, аны иҗтимагый тормыш белән бәйләнештә караганнар һәм уңай хәл итү юлларын алар теләгенә дә буйсындырганнар.

Өченче бүлектә Р.Фәхреддин мәгърифәтче һәм педагог буларак ачыла. Галимнең мәгърифәтчелек карашлары, дәреслекләр чыгару өлкәсендә эшчәнлеге өйрәнелә. Авторның алар белән танышлыгы, урынлы китерә алуы күренеп тора, һәм хезмәтнең әнә шул ягы аның дәлиллек дәрәҗәсен күрсәтеп, көчәйтеп тора да.

Дүртенче бүлектә Р.Фәхреддиннең дин белгече, фәлсәфәче булуы раслана. Галимнең Ислам фәлсәфәсен кабул итүе, казыйлык эшчәнлеге киң җәелдерелә. Р.Фәхреддин мисалында Рузия Зөфәр кызы ничек итеп мәгърифәтче иҗатына форма ноктасыннан гына түгел, эчтәлек, шул исәптән проблематика һәм идея-эстетик фикер ноктасыннан да тәэсир итүен ачык күрсәтә алган.

Бишенче бүлектә Р.Фәхреддиннең мөхәррирлек эшчәнлеге тикшерелә. Галимнең бу елларда тарихчы, ислам белгече һәм башка юнәлешләрдә ачылуы күзәтелә.

Йомгак өлешендә "Р.Фәхреддин мирасы һәм татар дөньясы" электив курсы буенча тикшерү-реферат яклау күздә тотыла.

Авторлык эше татар мәктәпләренең татар телендә сөйләшүче укучыларының яшь, белем үзенчәлекләрен дә истә тотып, яңа стандартларга туры китереп эшләнелгән.

Фикерләр урынлы, укучы өчен кызыклы, укучының фикер үсешен үстерә, аларны мөстәкыйль өйрәнергә, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә.

Язучының әсәрләре аркылы тарихыбызга күзәтү характерындагы белешмә-сораулар укучының эрудициясен арттыра. Һәр мәктәп укытучысына алдан ук зур әзерлек белән дәрескә керергә туры килә. Әлбәттә, әлеге хезмәт укытучылар өчен бик зур ярдәмлек булып тора.

Автор хезмәтне башкаруда үзен чиктән тыш җаваплы, хезмәт һәм фән сөючән итеп күрсәтә. Бик күп чыганаклар һәм теоретик материал белән таныштыра, бу аның эшендә дә бик ачык чагыла: Билгеле, Гаделшина Рузия Зөфәр кызы методик кулланмалар, тестлар төзүдә республика күләмендә тәҗрибәләре зур, шунлыктан бу хезмәт фәнни яктан төгәл эшләнгән. Темаара бәйләнеш сакланган, билгеле бер эзлеклелек, системалылык бар. Хезмәт эше теоретик тирәнлек, фикернең эзлеклелеге, мисалларны фәнни җирлек белән тыгыз бәйләү күзәтелә, шунлыктан ул хәтта электив курс эшенә куелган таләпләрдән югарырак таләпләргә дә җавап бирә дигән тәэсир калдыра. Әлбәттә, мисалларны тагын да күбрәк китерергә, әдәби дөньяны бик мулдан чагылдырырга була, авторның моңа мөмкинлекләре дә бар, әмма ул вакытта хезмәтнең күләме тагын да артып китәчәк. Хезмәт катлаулы, күпбаскычлы, шул ук вакытта һәрберсе дә композиция тудыру чараларын ачуга юнәлтелгән бүлекләрдән оеша. Монда язучының иҗат лабораториясе, ягъни фабула һәм сюжет уйлаудан детальләрне эшләп бетерүгә таба барган хезмәт тәртибе ачык чагыла.

**Гөлүсә Каюмова** филология фәннәре кандидаты,
Казан (Идел буе) федераль университеты доценты

ИНСТИТУТ ФИЛОЛОГИИ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ ИМ. ЛЬВА ТОЛСТОГО

КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ФГАОУ ВО «КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»
ОГРН 1021602841391 ИНСТИТУТ ФИЛОЛОГИИ И МЕЖКУЛЬТУРНОЙ КОММУНИКАЦИИ ИМ. ЛЬВА ТОЛСТОГО
ПОДПИСЬ Каюмовой Г.Ф. заверяю
Документовед
КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ

## Аңлатма язуы

“Ризаэддин Фәхреддин мирасы һәм татар дөньясы” дип аталган электив курс программасы гуманитар профильгә юнәлеш тоткан гомумбелем бирү уку йортлары өчен тәкъдим ителә. Бу программаның нигезенә өч әдәби чорны ( Мәрҗаниләр дәвере, XX йөз башы, Октябрь революциясеннә соңгы елларны) бергә бәйләүче, аларның үсешенә үзеннән зур өлеш кертүче, зыялы, укымышлы нәсел вәкиле- күренекле тарихчы әдип. Рухани, философ, мәгърифәтче язучы, библиограф, журналист, археограф Ризаэддин Фәхреддиннең күпкырлы эшчәнлеге һәм аның бай мирасының татар дөньясына керткән өлеше турында мәгълүмат салынган.

**Электив курсның эчтәлеге** интеграль характерда. Шуңа күрә бу курсны тарихчы да, әдәбиятчы да, дин әһеле дә тигез дәрәҗәдә файдалана ала.

**Электив курсның максаты-** Ризаэддин Фәхреддин шәхесе үрнәгендә һәм аның бай мирасына таянып, укучыларда милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре турында рухи һәм әхлакый нормалар формалаштыру.

**Электив курсның бурычлары:**

1.Күренекле галим Р. Фәхреддин шәхесе үрнәгендә укучыларга татар милли минталитетының характерлы үзенчәлекләрен күрсәтергә.

2.Фән эшлеклесе, күпкырлы талант иясе Р. Фәхреддин турында түбәндәге юнәлешләрдә белем бирергә:

-мәгърифәтче һәм педагог;

-әдәбиятчы галим һәм тәнкыйтьче;

-тарихчы, библиограф һәм археограф;

- дин әһеле һәм фәлсәфәче.

3.Тәрбия өлкәсендәге үгет-нәсыйхәтләре ярдәмендә укучыны үз әхлагын формалаштыручы шәхес итеп тәрбияләргә.

**Программаның билгеләнеше:**

Электив курс материалы X-XI сыйныф укучыларына туры килә. Түбәндәге юнәлешле мәгариф оешмаларында кулланыла ала:

-гомуми белем бирү мәктәпләрендә;

-төбәк һәм мәктәп компоненты буларак, гуманитар профильдәге сыйныфларда

**Электив курсның төп функцияләре:**

1. Гуманитар юнәлешле укучыларның милли үзаңы формалашу өлкәсендәге танып- белү эшчәнлекләрен тирәнәйтү функциясе;
2. “Татар мәгърифәтчеләре” махсус курсына өстәмә;
3. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларына һәм тәрбия өлкәсендә эшләүче сыйныф җитәкчеләренә түгәрәк эш планы буларак.

**Электив курсның актуальлеге:**

Белем эшчәнлеген гуманлаштыру һәм шул нигездә толерант шәхес тәрбияләү- заман педагогик теорияләрен характерлаучы төп сыйфат. Мәгариф оешмаларында бу максат, һичшиксез, гуманитар цикл предметлары һәм тәрбияви чаралар аша гамәлгә ашырыла. Бу принциптан караганда, даны бөтен төрки, хәтта ки ислам дөньясына киң таралган, Европа, Америка илләрендә яхшы мәгълүм булган акыл иясе Р. Фәхреддиннең мирасын барлау, кылган гамәлләрен һәм иҗатын өйрәнү, аларга объектив бәя бирү- электив курсның актуальлеген раслаучы бер дәлил.

**Программа эчтәлегенең төзелеше:**

Программа 5 бүлектән тора һәм һәр бүлек үз эчендә темаларга бүленгән.

Кереш:

1. Р. Фәхретдиннең тарихи эшчәнлеге.

2. Галимнең әдәби һәм тәнкыйди эшчәнлеге.

3. Р.Фәхреддин- дин әһеле һәм фәлсәфәче.

4.Р. Фәхреддин-мөхәррир.

**“Ризаэддин Фәхреддин мирасы һәм татар дөньясы” электив курсы буенча укучылар белергә тиешле белем һәм күнекмәләр:**

1. Р. Фәхреддин яшәгән чорның иҗтимагый, сәяси, мәдәни һәм әдәби үзенчәлекләрен аера белергә.
2. Бу чорның тулаем татар дөньясы яшәешенә керткән өлеше турында күзаллау булдырырга.
3. Күпкырлы галим Р. Фәхреддиннең тормыш юлы һәм иҗади мирасы турында тарафдар булырга.
4. Р. Фәхреддин мирасының татар әдәбияты, мәдәнияты һәм тарихына керткән өлеше һәм аның әһәмиятен аңлата белергә.
5. Әдәби әсәрләренә анализ ясый белергә.
6. Тәрбияви һәм әхлакый хезмәтләрендә, аның үгет-нәсыйхәтләренә таянып, үз шәхесләрен формалаштыру юнәлешендә эш алып барырга.
7. Татар мәгърифәтчеләре К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Курсави һәм башкалар рәтендә Р. Фәхреддиннең лаеклы урын тотуын аңларга.
8. Р. Фәхреддин иҗаты буенча үзләштерелгән белемне гамәлдә кулланырга

## “Ризаэддин Фәхреддин мирасы һәм татар дөньясы” электив курс программасының эчтәлеге

**Кереш** “Ризаэддин Фәхреддин мирасы һәм татар дөньясы” электив курсының максаты һәм бурычлары. Р. Фәхреддиннең мәдәни һәм иҗтимагый тормышта тоткан урыны. Аның тормыш юлы һәм иҗади мирасы. Библиографик чыганаклар белән танышу.

**I бүлек.** Р. Фәхреддиннең тарихи эшчәнлеге.

Галимнең тарих фәне алдына куйган бурычлары. Р. Фәхреддин карашынча милләт төшенчәсе. Казан ханлыгы һәм Алтын Урда чоры ханнары турында белешмәләр. Татар тарихын өйрәнү өлкәсендәге энциклопедик хезмәтләре.

**II бүлек.** Р. Фәхреддиннең әдәби һәм тәнкыйди эшчәнлеге.

Р. Фәхреддин- киң карашлы әдәбият белгече. Галимнең мөселманлык концепциясе. Татар проза жанрын үстерүдә тоткан урыны. Сәяхәтнамәләр жанрына нигез салуы. Әдәбият теориясе буенча мәгълүматлы галим булуы. Татар әдәбиятын Көнчыгыш әдәбияты белән бәйләнештә каравы. Әдәбият тарихын, әдипләрнең тормыш юлын, иҗатын халыкка җиткерүдәге роле. Әсәрдә хатын-кызлар мәсьәләләрен яктыртуы.

**III бүлек.** Р. Фәхреддин мәгърифәтче һәм педагог.

XIX гасыр азагында җәдитчелек хәрәкәте. Галимнең мәгърифәтчелек карашлары. Мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртеп кору, дөньяви фәннәрне укыту буенча яңа проектлар тәкъдим итүе. Дәреслекләр ( татар морфологиясе) чыгару өлкәсендә эшчәнлеге.

Милли тәрбияне тулы системада күз алдына китерүе. Гаилә тәрбиясе, мәктәп-мәдрәсә тәрбиясе. Ата-ана булу мәсьәләләре, җәмгыятьтә хатын-кызның, ананың, атаның роле. Әхлак мәсьәләләренә багышланган унбер исемдәге күпсанлы хезмәтләр чыгаруы.

**IV бүлек.** Р. Фәхреддин дин белгече һәм фәлсәфәче. Бу дәвердә фәлсәфәнең торышы. Галимнең фәлсәфи карашларының формалашу җирлеге. Ислам фәлсәфәсен кабул итүе.

Казыйлык эшчәнлеге, “Ахун”дәрәҗәсе бирелүе. Аның бу юнәлештә дини, дини-хөкем һәм гыйльми эшчәнлеге.

**V бүлек.** Р. Фәхреддиннең мөхәррирлек эшчәнлеге.

Тарихи-педагогик, фәнни-популяр “Шура” журналының чыга башлавы. Галимнең бу елларда тарихчы, ислам белгече һәм башка юнәлешләрдә ачылуы.

Татар әдәбияты үсешендә “Шура” ның роле. Журналда халык тарихына, аның этногенезына кагылышлы мәсьәләләр яктыртылышы.

“Вакыт” газетасында эшчәнлеге.

**VI бүлек.** “Р. Фәхреддин мирасы һәм татар дөньясы” электив курсы буенча белемнәрне тикшерү- реферат яклау.

**Электив курсның укыту-тематик планы**

| Бүлек | Дәрес саны | Дәрес темасы | Дәрес тибы |
|---|---|---|---|
| Кереш | 1 | “Ризаэддин Фәхреддин мирасы һәм татар дөньясы”электив курсының максаты һәм бурычлары. XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы мәдәни һәм иҗтимагый тормышына бәя | Кереш дәрес |
| | 2 | Ренеанс чорының күренекле вәкиле Р. Фәхреддин турында гомуми белешмә. Библиографик чыганакларга күзәтү. | Дәрес-лекция |
| | 3 | Галимнең тормыш юлын өйрәнү:<br>-Туган якта (1859-1891) | Дәрес-практикум |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | -Уфада (1891-1906)<br>-Оренбургта (1906-1918)<br>-Уфада (1918-1936) | |
| | 4 | Иҗаты турында гомуми белешмә. Р. Фәхреддиннең XIX гасыр ахыры XX гасыр башындагы иҗаты (1859-1917) | Күзәтү дәресе |
| | 5 | Р. Фәхреддин Совет чорында (1917-1936) | Күзәтү дәресе |
| I бүлек | 6 | Р. Фәхреддиннең тарихи эшчәнлеген барлау | Дәрес-лекция |
| | **7** | Р. Фәхреддиннең татар халкының килеп чыгуына кагылышлы карашларын ачыклау | Дәрес-практикум |
| | 8 | Р. Фәхреддиннең “Болгар вә Казан төркләре” китабы белән таныштыру | Дәрес-лекция |
| | 9 | Р. Фәхреддиннең “Болгар вә Казан төркләре” китабындагы язмаларны уку һәм анализлау | Дәрес-практикум |
| | 10 | Р. Фәхреддиннең “Казан ханнары” һәм “Алтын Урда ханнары” китаплары | Семинар дәрес |
| | 11 | Р. Фәхреддиннең “Ибн-Фадланның Болгарга килүе” китабы | Дәрес-диалог |
| | 12 | “Асар” (“Эзләр”)-библиографик хезмәте һәм аның тарих, әдәбият өлкәсендәге әһәмияте | Күзәтү дәресе |
| II бүлек | 13 | Р. Фәхреддиннең әдәби эшчәнлеге турында фикер алышу | Дәрес-әңгәмә |
| | 14 | “Сәлимә, яки гыйффәт” (1898) | Дәрес-практикум |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | повесте, аны уку | |
| | 15 | “Сәлимә, яки гыйффәт” (1898) повестен анализлау | Дәрес-әңгәмә |
| | 16 | “Әсма, яки гамәл вә җәза” романы, аны уку | Дәрес-практикум |
| | 17 | “Әсма, яки гамәл вә җәза” романын анализлау | Дәрес-диспут |
| | 18 | Р. Фәхреддин әсәрләрендә хатын-кыз бәхете темасының яктыртылышы | Дәрес-әңгәмә |
| | 19 | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. “Р. Фәхреддин әсәрләрендә хатын-кыз бәхете” | Сочинение язу |
| | 20 | Р. Фәхреддиннең тәнкыйди эшчәнлеге | Дәрес-лекция |
| III бүлек | 21 | Р. Фәхреддин мәгърифәтче һәм педагог | Ачык сыйныф сәгате |
| | 22 | Р. Фәхреддиннең “Нәсыйхәт” китаплары:<br>- Нәсыйхәт I (малайлар өчен)<br>- Нәсыйхәт II (кызлар өчен)<br>- Нәсыйхәт III (олылар өчен) | Ачык сыйныф сәгате |
| | 23 | “Тәрбияле ата”, “Мәшһүр адәмнәр” | Дәрес-практикум |
| | 24 | “Тәрбияле ана”, “Мәшһүр хатыннар” | Дәрес-практикум |
| | 25 | “Тәрбияле бала”,”Шәкертлек әдәбе” | Дәрес-практикум |
| | 26 | “Әхлак гыйлеме” | Дәрес-әңгәмә |
| | 27 | “Юаныч” китабы | Дәрес-әңгәмә |
| IV бүлек | 28 | Р. Фәхреддин хезмәтләрендә Ислам дине | Дәрес-лекция |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 29 | Дини, фәлсәфи хезмәтләре. “Ислам дине” һәм “Коръәни Кәрим тәфсире” китаплары | Дәрес-лекция |
| | 30 | Р. Фәхреддиннең Европа һәм шәрыкъ фәлсәфәсенә карашы | Дәрес-лекция |
| | 31 | “Җәвамигуль –кәлим шәрхе” хезмәте | Дәрес-практикум |
| | 32 | Р. Фәхреддиннең вакытлы матбугат юнәлешендәге әдәби эшчәнлеге | Дәрес-лекция |
| | 33 | Электив курс буенча контроль төре: реферат язуга хәзерлек, таләпләр | Дәрес-әңгәмә |
| | 34 | Төрле темаларга башкарылган рефератларны яклау | Дәрес-практикум |

**Реферат өчен темалар**

1. Р. Фәхреддин иҗатында гуманизм идеяләре.
2. Р. Фәхреддиннең педагогик мирасында рухи-әхлакый проблемалар.
3. Р. Фәхреддин иҗатында хатын-кыз бәхете темасының татар әдәбиятында чагылышы.
4. Р. Фәхреддиннең хезмәтләрендә толерантлык проблемалары.
5. Р. Фәхреддин -әдип һәм әдәбиятчы.
6. Р. Фәхреддин һәм М. Бигиев иҗатында тема уртаклыгы.
7. Үз шәхесеңне тәрбияләүдә Р. Фәхреддиннең мирасын файдалану.
8. Р. Фәхреддиннең дини эшчәнлеге.
9. Р. Фәхреддин – тарихчы һәм энциклопедист.
10. Р. Фәхреддин иҗатында мәгърифәтчелек идеяләре.

**Укытучылар өчен әдәбият исемлеге**


1. Ризаэддин бине Фәхреддин. Ислам дине нинди дин?// Мирас.-1991.-1, 1992.-1

2. Ризаэддин бине Фәхреддин. Ибне Фадланның Болгарга килүе.// Мирас.-1994.-5/6.
3. Ризаэддин бине Фәхреддин. Казан ханнары.-Казан: Тат.кит. нәшр., 1995.
4. Ризаэддин бине Фәхреддин. Алтын Урда ханнары-Ханы Золотой Орды.-Казан: Тат. Кит. Нәшр., 1996
5. Ризаэддин бине Фәхреддин. Тәрбияле хатын: һәрбер өйдә вә һәрбер хатын кулында бу китаптан бер данәсе булырга тиешледер.-Казан: “Иман” нәшр.,1996
6. Ризаэддин бине Фәхреддин. Тәрбияле бала.// Тәрбия.-1999.-7
7. Ризаэддин бине Фәхреддин. Болгар вә Казан төрекләре.-Казан:Тат.кит. нәшр., 1993.
8. Әмирхан Рәвил. Риза Фәхреддинов – тарихчы.//Мирас.-1992. -12.
9. Баишев Ф. Н. Общественно-политические и инравственно-этические взгляды Ризы Фахреддинова.-Уфа: Китап. -1996.
10. Гайнуллин М. Риза Фәхретдинов.// Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. 2 том. XIX йөз татар әдәбияты.- Казан: Тат.кит.нәшр., 1985.-319-334
11. Госманов М. Катлаулы чорның күренекле вәкиле.// Казан утлары.-1984-1.-142-157 б.
12. Рәхимкулова М. Р.Фәхреддиннең педагогик карашлары.// Хәзинә.-1999.-21 нче гыйнвар.
13. Ризаэддин Фәхреддин: мирасы һәм хәзерге заман. Мәкаләләр җыентыгы.- Казан.-2003.- 332 б.
14. Хәйруллин Әнвәр. Күпкырлы галим.// Социалистик Татарстан.-1989.-10 нчы февраль
15. Шәрәфетдинов З. Т., Даутов Г. Ф., XX йөз башы татар мәгарифе тарихында Ризаэддин Фәхреддин. – Яр Чаллы. “Идел-йорт” нәшрияты.2000.-92 б.

**Укучылар өчен әдәбият исемлеге**

1. Ризаэддин бине Фәхреддин. Нәсыйхәт. Ялгыз кыз балалар өчен.// Мәгариф.-1992.-6.-53-54 б.

2. Фәхреддинов Р. Әсма, яки гамәл вә җәза. Татар әдәбияты. XIX йөз. – Казан: Тат. Кит.нәшр.,1968.-630-670 б.

3. Фәхреддинов Р. Әсма, яки гамәл вә җәза. Татар мәгърифәтчелек әдәбияты (1860-1905). Казан: Тат.кит.нәшр., 1979. -312-352 б.

4. Фәхреддинов Р. Сәлимә, яки гыйффәт. Татар мәгърифәтчелек әдәбияты (1860-1905). Казан: Тат.кит.нәшр., 1979.-264-311 б.

5. Карурманны чыккан чакта...: XIX гасыр әдәбияты. Казан: Мәгариф, 2001.-319 б.

6. Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. Ризаэддин Фәхреддин.// урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбияты.- Казан: “Китап” нәшр., 1998. 272-276 б.

7. Шаһиев Р. Ризаэддин бине Фәхреддиннең тормыш юлы һәм иҗади мирасы.-Әлмәт.-2004.

8. Госманов М. Ризаэддин Фәхреддин мирасы.// Үткәннән-киләчәккә: Фәнни-публицистик мәкаләләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1990. -51-72 б.

9. Гайнуллин М. Татарская литература XIX века. – Казань:Тат. кн.изд-во, 1985.

10. Ризаэддин Фәхреддин. Фәнни – библиографик җыентык.// Казан: “Рухият” нәшр. -1999.

## Дәрес планы

**Тема:** Яман гадәтләрдән саклан! (“Юаныч” китабына күзәтү ясаганнан соң үткәрелә)

**Максат**: Укучыларга саулыкның матур гомер итү өчен мөһим шарт икәнлеге турында тәрбия бирү, яшь буынны сәламәт яшәү рәвешенә өйрәтү, зарарлы гадәтләрнең сәламәтлеккә зыян китерүен аңлату, олыларның, эти-әниләренең киңәшләренә колак салырга өндәү.

**Җиһазлау:** дәреслек, презентация, Р.Фәхреддин нәсыйхәтләре, “Мәгариф ” журналлары, мәкальләр.

**Дәрес барышы:**

**1.Оештыру өлеше.**

- Исәнмесез, укучылар. Кеше дөньяга яшәр өчен туа. Ә яшәү өчен сәламәтлек кирәк. "Сәламәтлек – иң зур байлык” диләр. Чөнки ул булмаса, кеше бик күп нәрсәләрдән мәхрүм. Сәламәтлек - кеше бәхетенең нигезе. Исәнлек булганда гына кеше үзенең теләк-омтылышларына ирешә ала. “Адәм баласының иң зур байлыгы - тәне вә җаны сәламәт булу. Әмма күп вакыт без бу байлыкның кадерен белмибез. Бөтен дөньяның хуҗасы булсаң да, тәнең сәламәт булмаса, рәхәтлек сизмәссең”. Р.Фәхреддин

**2. Актуальләштерү.** Укучылар, ничек уйлыйсыз, без бүген нинди темага сөйләшербез?

- Әйе, без бүген сезнең белән бүген саулыкның иң зур, иң кирәкле нәрсә икәнлеге, аның байлык булуы турында сөйләшәчәкбез. Максатыбыз – сәламәтлек - кешегә табигать биргән иң зур байлык икәнлеген исбатлау. Сәламәт тормыш рәвеше – кешенең һәрьяклап үсешен, хезмәткә сәләтлелеген, рухи байлыгын, сәламәтлеген тәэмин итә торган билгеле бер кагыйдәләрне үтәү ул. Кеше сау-сәламәт булсын өчен нинди кагыйдәләрне үтәргә тиеш?

**Укучылар:**

1. Төрле физик күнегүләр, хәрәкәтле уеннар - сәламәтлекне ныгытучы чаралар. (укытучы: әйе, даими шөгыльләнгәндә генә аларның файдасы булыр).

2. Гимнастика ясау (Иртәнге гимнастиканың кешегә никадәр файда китергәнен белеп торуга карамастан, бик күпләр аны ясамый. Ялкаулыкларын вакыт юклык белән акларга тырышалар. Ләкин зарядкага киткән вакыт бушка үткән вакыт түгел. Ул кәефне күтәрә, дәрт өсти, эшчәнлекне арттыра).

3. Сәламәт яшәргә теләгән кеше чисталыкны бар урында да сакларга тиеш (тешләрне һәр көнне ике тапкыр чистартырга, атна саен мунча керергә, чәчне тарап, юып йөрергә, тырнакларны кисәргә, салкын су белән юынырга),

4. Тәмәке тартмаска, спорт белән шөгыльләнергә тиеш.

**3. Өйгә эшне тикшерү**. Сез тазалык – саулык , сәламәтлек турында нинди әйтем яки мәкальләр беләсез?

- Сәламәтлекне саклыйсың килсә, һәр эшеңдә сак бул (Ризаэддин Фәхреддин. мәгърифәтче);

- Мин белгән бердәнбер матурлык – ул саулык (Генрих Һейне, немец язучысы);

- Сәламәт кеше – табигатьнең иң кыйммәтле җимеше ( Томас Карлейль, инглиз акыл иясе);

- Ходай сакланганны саклармын дигән;

- Байлык – бер айлык, саулык– гомерлек;

- Саф һава – тәнгә дәва;

- Сәламәтлек – җәүһәр , ләкин тиз югала;

- Саулыкны сатып алып булмый ( “Чирнең сәбәбен белеп, аны китереп чыгаручы нәрсәләрдән сакланырга кирәк. Мәсәлән, тирләп салкынга чыгу, исле (күмер исе, агулы ис) бүлмәдә тору, майлы ризыклар ашау, исерткеч эчемлекләр эчү, әфьюн кабу - болар барысы да чирләүгә китерә”. Р.Фәхреддин).

- Дөрес, укучылар, әлеге мәкаль һәм әйтемнәрнең эчтәлегеннән күренгәнчә, һәркемнең бәхеткә хакы бар. Сәламәтлек бәхеткә тиң сүз. Шулай булгач, сезнең тазалыгыгыз– саулыгыгыз үз кулыгызда.

**4. Белемнәрне ныгыту.**

Бу теманы үткәндә нинди зарарлы гадәтләр белән таныштык, искә төшерик әле.

**1 нче укучы:** Тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр һәм наркотиклар куллану – иң начар, зарарлы гадәтләр. Тәмәке тарту үпкәләр өчен, алай гына да түгел, бөтен оргнизм өчен бик зарарлы. Тәмәке тарта башлаган бала начар үсә, эшләгәндә тиз арый, белемне начар үзләштерә, еш авырый. Болар барысы да тәмәке төтенендә куркыныч агу – никотин һәм күп кенә башка зарарлы матдәләр булудан килә. Тәмәке тартмый торган кешенең үпкәсе алсу төстә, ә тәмәке тартучының үпкәсе зарарлы матдәләрдән соры төстә була. Галимнәр һәр тартылан сигареттан кешенең гомере 15 минутка кыскаруын исәпләп чыгарганнар.

**2 нче укучы**: Спиртлы эчемлекләрне авызыңа да алма! Спиртлы эчемлекләрдә була торган спирт (алкоголь) , чамадан тыш кулланганда, ашказаны һәм башка органнар авыруларын китереп чыгара, бөтен организмның эшчәнлеген боза. Исерткеч эчемлекләр эчү балалар өчен бигрәк тә куркынычлы. Хәтта берничә йотым алкоголь бала органимын көчле агуларга мөмкин.

**3 нче укучы:** Наркотикларга якын да килмә! Наркотиклар – кеше организмына үтергеч тәэсир итә торган үзенә бер төрле матдәләр алар. Наркотикны бер яки ике тапкыр кулланган кеше аңа күнегә һәм аннан башка яши алмый башлый. Андый кешедә наркомания дигән, дәвалап булмый торган куркынычлы авыру барлыкка килә. Наркотик минең, бөтен организмның эшләвен боза, һәм ахыр чиктә кеше үлә. Наркотикларны тарату – зур җинаять, аның өчен каты җәзага тарталар.

- Әйе, укучылар, кеше җир йөзендә бер тапкыр гына яши. Безгә үзебезнең гомеребезнең кадерен белеп, сау-сәламәт булып яшәргә кирәк.

**5. Белемнәрне тикшерү.**

- Әйдәгез, викторина сорауларына җавап бирик әле.

1. Ни өчен тәмәке тартырга ярамый? ( тәмәке тарткан кешенең тешләре, бармак тиресе саргая, авызыннан тәмәке исе килә, ул еш йөткерә)

2. Башны ничә көнгә бер мәртәбә юарга кирәк? ( 3-4 көнгә бер мәртәбә юарга кирәк)
3. Ни өчен тырнакларны чәйнәргә ярамый? ( тырнак астында зарарлы микроблар була)
4. Ни өчен кешенең өс, баш, аяк киемен кияргә ярамый? ( тире авырулары очрарга мөмкин) “Тән һәм киемнәрне, урын-җирләрне чиста тоту, тәһарәт алу, госел коену, намаз уку, ураза тоту, өй эчендәге хезмәтләрне башкару- сәламәтлек күнекмәләредер” - ди Ризаэддин Фәхреддин “Нәсыйхәт” дигән хезмәтендә.
5. Спиртлы эчемлекләр эчү кешенең сәламәтлегенә һәм тышкы кыяфәтенә нинди зур зыян китерә? ( ашказаны, бавыры бозыла, гомере 15-17 елга кыскарак була)
Р.Фәхреддин сүзләрен мисалга китерү: “Һәртөрле усаллык вә начарлык аракыдан туа”. Укучылар, бөек галимебез Р.Фәхреддин "Юаныч” исемле китабында начар гадәтләрдән саклану чараларын ачык күрсәтеп: тәмәкененең кеше сәламәтлеге өчен зарарлы булуын, исерткеч эчүдән котылу чаралары турында бик күп кыйммәтле мәгълүматлар яза. Наркомания, СПИД кебек бик яман авырулар чәчәк аткан вакытта, әхлагыбыз Р.Фәхреддин аңлаган дәрәҗәдән бик күпкә түбән төшкән заманда, бу нәсыйхәтләрне өйрәнү безгә бик зарур.
**6. Өй эше.** Р.Фәхреддинның "Юаныч” исемле китабыннан бүгенге темага туры килгән гыйбрәтле сүзләрне язып алырга.
**7. Рефлексия.**
- Дәрескә куелган максатларга ирештекме?
- Нинди яңалыклар алдыгыз?
Әйе, укучылар, бүген без сезнең белән сәламәтлеккә тискәре йогынты ясаучы зарарлы гадәтләр турында сөйләштек. Сәламәтлекнең зур байлык икәненә тагын бер кат инандык. Чөнки сәламәт кеше генә тормышны ярата. Әгәр кеше табигать биргән табиблардан – кояш яктысын, саф һаваны, чиста суны, физик күнегүләрне, ялны дөрес файдаланса, ул бер дә авырмас. Сәламәт булыйк!

**Лекция-дәрес**

# Күренекле мәгърифәтчеләребез иҗатын өйрәнеп, бүгенге тормышны Ислам дине аша бәяләү

## Кереш

“Татар халкының күренекле фикер иясе, мәгърифәтче, тарихчы, педагог, язучы, журналист, олуг дин әһеле Р.Фәхреддин – иҗаты хезмәтләре белән төрки-татар дөньясында тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе.”

Т.Ш.Гыйлаҗев.

**Максатлар** :

- **1)** Татар мәгърифәтчелеләренең ислам диненә карашларын күзәтү.
- **2)**Ризаэддин Фәхреддин әсәрләрендә Ислам диненең чагылышын ачыклау
- **3)** Кешелек сыйфатларын саклап калуда бердәнбер юл – Исламга килүнең әһәмиятен ачу.
- **4)** Дин һәм бүгенге туган телебезнең язмышы турында уйланулар.

Теманың **актуальлеге**. Бүгенге көндә актуаль проблемаларның берсе булып Ислам диненең үзгәрүе тора. Кешеләрнең бер-берсенә карата мөнәсәбәтләре үзгәрә, хөрмәт дигән сүз бөтенләй онытылып бара. Кеше әдәп-әхлак тәрбияләрен оныта. Соңгы елларда балаларның тәрбия, әдәп-әхлак, үз-үзләрен тотыш дәрәҗәсе бик түбән төште, йомшады, какшады. Киләсе буын рухи яктан чери, әхлакый яктан таркала башлады.Без әйләнә-тирәдәгеләрне хөрмәт итә беләбезме?Әдәп-әхлак нормалары – киләчәк буынның нигезе була алырмы? Бу мәсьәләләрне ачыклау өчен, Р. Фәхреддин хезмәтләренә таяндым

## I бүлек

## Татар мәгърифәтчелеләренең ислам диненә карашлары

Ризаэддин Фәхреддин гомере буе тәрбия эшенә зур әһәмият бирә: “Тәрбия – акрынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер... Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия иң кирәкле бер эш булачактыр”- ди ул.

Җәмгыятьтә тәртип һәм рухи үсешне тәэмин итүче чыганакларның иң мөһиме - әдәп-әхлак, ә күркәм әхлакның нигезе – дин, иман. Аллаһы Тәгалә кешеләргә туры юлны күрсәткән, хәләлне хәрамнан аерган һәм аларның чикләрен төгәл билгеләнгән. Шул кануннар буенча яшәгәндә генә кеше бәхеткә, уңышка ирешә ала, дөньялыкта тормышы бәрәкәтле, ә ахирәттә киләчәге өметле була. (“Иман дәресләре” Вил Казыйханов).

XIX гасырда, бигрәк тә аның икенче яртысында , Россиядә феодаль тәртипләр таркала барып, капиталистик, буржуаз мөнәсәбәтләр үсә. Бу үзгәрешләр, акрынлап булса да, татар халкы арасында да бара. Шуның нәтиҗәсендә иске феодаль-патриархаль тәртипләргә, торгынлыкка каршы буржуаз-демократик хәрәкәт буларак, татарлар арасында мәгърифәтчелек хәрәкәте формалаша.

Бу чор поэзиясендә дә төп ике юнәлеш күзгә ташлана. Берсе-дини суфичылык йогынтысындагы тармак. Икенче юнәлеш исә дөньяви-реалистик характерда. Бутармакның иң күренекле шагыйре-Габделҗәббар Кандалый. Мәдрәсәләрдә дини-дидактик әдәбият һәм суфичылык рухындагы әсәрләр күп укылган. Кандалый да шушы традицияләрдә тәрбияләнгән. Шуның нәтиҗәсе буларак, үзе дә дини-әхлакый юнәлештә үгет-нәсыйхәт бирүче поэма язган. Әсәрнең исемен “Рисаләил-иршад”, ягъни “Тугры юлга күндерүче китап” дип атаган. Поэма керештән, 28 бүлектән һәм йомгак рәвешендә урнаштырылган “мөнәҗәт”тән гыйбарәт.

Әлеге әсәрдә дини-суфичылык китапларында күп әйтелгән фикерләр кабатлана: фани дөнья бик тиз үтә, аның кызыкларына алданмаска, ахирәткә якты йөз белән бару өчен, юлга “азык; ягъни изге эш-гамәлләр булдырырга кирәк, әҗәл уты гомерне кинәт өзәргә мөмкин.

Мәгърифәтче язучыларны нинди мәсьәләләр борчый иде соң? Алар күбрәк нәрсә турында язалар? Әлбәттә инде, халыкны агарту, милләтне мәгърифәтле һәм мәдәниятле итү турында. Бу мәсьәләләр иң башлап М. Акъегетзадәнең “Хисамеддин менла” романында күтәрелә.

М. Акъегетнең “Хисаметдин менла” романы әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан үз заманында зур яңалык буларак кабул ителә. Ул, шул

чорның әдәби тәнкыйте билгеләгәнчә, татар әдәбиятының идея-эстетик яңаруын күрсәткән беренче әсәрләрдән була һәм җәдитчелек әдәбиятына башлангыч бирә.

Вакыйгаларда төп урынны алып торган Хисаметдин белән Хәнифә – һәрьяклы камил затлар. Белемлелектә, әхлаклылыкта, ирекккә омтылышта үз тирәлекләрендә аларга тиңнәр юк. Әдип нәкъ менә шундый кешеләр җәмгыятьтә югары бәяләнергә, тормышта бәхеткә ирешергә, бер-берсенә пар булырга тиеш дип саный.

Хисаматдин белән Хәнифә – язмышка, традицияләргә каршы баручы яшьләр. Егет язмыш мәсьәләсендә әнисе белән бәхәскә керә, кыз исә, ата-анасы ризалыгыннан башка, икенче кешегә кияүгә чыгарга җөрьәт итә, бар кешене аптырашта калдырып, туй алдыннан йортыннан чыгып кача.

М. Агъегет мәгърифәтле кешегә дә бәхетнең үзеннән-үзе килмәвен, аны көрәшеп алырга кирәклеген, җәмгыятьнең аларга каршы киртәләр коруын тасвирлый. Димәк, ул мәгърифәтле актив шәхес проблемасын алгы планга чыгара.

Мифтәхеддин Акмулланың иҗаты да зур роль уйный. Шагыйрьнең шәхесе һәм әсәрләре инде менә йөз елдан артык татар, казах, башкорт укучыларының, әдипләренең һәм галимнәренең игътибар үзәгендә. Г. Ибраһимов, мәсәлән, Акмулланы “беренче яңа уйгану хәбәрчесе” дип атый.

Акмулланың тормыш юлын һәм иҗат мирасын өйрәнүгә аеруча Ризаэддин Фәхреддин зур өлеш керткән. Галим шагыйрьне күреп тә белгән. Ул Акмулланың “зирәк вә үткен табигатьле һәм игътибарлы” кеше булуын әйтеп калдырган.

Мәгърифәтче шагыйрьнең иҗаты өч юнәлештә үсә. Беренчедән, ул, мәгарифне алга җибәрү юлында армый-талмый эшләгән затларны үрнәккә куеп, аларның якты образларын тудырып, алар үрнәгендә мәгърифәтле булырга чакырып, гомумән, мәдәни алгарышны яклап әсәрләр яза. Икенчелән, иҗтимагый гаделсезлекләр дөньясын фаш иткән шигырьләр

иҗат иткән. Дини мәсьәләләрне дә үз эченә алган фәлсәфи-әхлакый парчалары исә аның мирасының өченче төркемен тәшкил итә.

Шагыйрь үз замандашларын Әфләтун (Платон), Ш. Мәрҗани кебек Көнчыгышның һәм үзебезнең философларыбыз белән бик еш чагыштыра.

Шул ук вакытта әлеге танылган затларын тиңләрлек икенче шәхесләр белән дә таныш. Мәсәлән, ул Мәрҗанине имам Газали янәшәсендә күрә. Ике философ һәм дин галименең дөнья, бигрәк тә мөселман халыкларына карата кылган файдалы хезмәтләрен чагыштырсаң, бу бәяләүдә ни дәрәҗәдә гаделлек барлыгын күрәсең.

## II бүлек.

## Ризаэддин Фәхреддин әсәрләрендә Ислам диненең чагылышы

Динебез татар халкын иң авыр чакларда да исән-имин саклап калды, болганчык заманнарда да халкыбыз үз телен, гореф-гадәтләрен онытмады, иманын югалтмады. Дин - башка дөньяви фәннәр – химия, биология, физика, математика кебек үк фән икән. Әмма алардан аермалы буларак, ул дөньяны бүтән яссылыкта, ягъни дин, рух яссылыгында танып белергә өйрәтә.

Ислам – дөнья диннәре арасында иң яшь дин, 922 нче елның 16 мартында Болгарда кабул ителгән. Мөхәммәд пәйгамбәребез Аллаһы Тәгалә тарафыннан илче итеп җибәрелә. Ислам динен җир йөзендә бер миллиардтан артык халык тота, күпчелек Африка-Азия илләрендә аның дәүләт дине булып саналуын һәм Коръәннең изге китап булуын аңлата. Коръән китабы – ул кешелеклелек китабы. Коръән – хәдисләр һәм догалар җыентыгы гына түгел, ә яшәү өчен кирәкле булган гыйлем, үгет-нәсихәт, һәр адәмгә туган көненнән алып, аны соңга юлга озатканда да кирәкле фәлсәфи, юридик, әхлакый тәрбия китабы да.

Ризаэддин Фәхреддин  XIX гасыр азагы – XX гасыр башының бөек әдибе, тарихчысы гына түгел, бәлки мәшһүр дин галиме дә.Аның фикеренчә, ислам дине өч нигезгә таяна: игътикад( ышану), гамәл,( кәсеп гыйбадәт) һәм әхлак. “Ислам дине хисап бирү көненә дөрес дип ышанудан

һәм дә гамәл вә гыйбадәтләрне шәригать кушканча үтәүдән вә әхлакны төзәтүдән гыйбарәт”,- дигән ул. Димәк, тәрбиясез, әхлаксыз кеше әле тулысынча мөселман булып җитә алмый. Бәлки шуның өчен дә, Риза Фәхреддин әлеге темага бик күп әсәрләр иҗат итә: “Тәрбияле бала”, “Тәрбияле ана”, “Тәрбияле ата”, “Тәрбияле хатын”, “Шәкертлек әдәбе”, “Нәсыйхәт”, “Әдәбе тәгълим”, Гыйлем әхлак” һ.б. Бары тик тәрбияле һәм әхлаклы кеше генә милләтенә ярдәмче була, үрнәк шәхес булып милләтен бөтен дөньяга таныта ала.

Әхлак тәрбиясе һәр өлкәдә һәрвакыт игътибар үзәгендә тора. Әхлакый тәрбия иң төп проблема булды һәм ул шулай булып калачак. Бүгенге тормышыбызда мәдәният һәм әхлаклылык дигән мөһим сыйфатларның какшавы нык чагыла. 70 ел эчендә илдә дин-иманның ни икәнен белмәгән берничә буын үсеп җитлекте. Аллага да, муллага да, ахирәткә дә, оҗмах-тәмугка да ышанмаган балаларыбызга әдәп, инсафлык, шәфкать, миһербанлылык кебек затлы төшенчәләр ят нәрсәгә әйләнде. Хәзер яшәешебезне билчән кебек баскан җинаятьчелек, әхлаксызлык, бозыклык, зина кылу, сүгенү, таш бәгырьлелек, битарафлык һәм башка яман галәмәтләр диннән, Аллаһы Тәгаләдән, имнаннан йөз чөерү аркасында чәчәк ата. Ә бит Аллага күңелдән ышанган, шәригатькә тугрылык саклаган адәм баласыннан җинаятьче берничек тә чыга алмый! Яшьләребезнең башка дин вәкилләре белән никахка керүе массакүләм төс алды. Бу афәт-гарасаттан Аллаһы Тәгаләгә сыену, шәригать нигезендә гамәл кылу, ата-анага, өлкәннәргә ихтирамлы, кешеләргә шәфкатьле булу, намуслы хезмәт, фәкыйрь-гарипләргә хәл кадәренчә ярдәм итү кебек гамәлләр генә коткара ала.

"Мәктәпнең вазифасы - фәкать гыйлем өйрәтү бәлән генә чикләнмичә, бәлки балаланың күңелләренә Алланы сөю, гүзәл гадәтләр, тырышу, эшлеклелек, туганлык, гайрәт, инсафлылык, гүзәл холык, гаделлек, батырлык, җанлылык кебек яхшылык орлыкларын чәчү вә тәрбияләп үстерү булачактыр..."- дип язган Риза Фәхреддин үзенең “Әдәбе тәгълим” китабында.

Тәрбия темасына багышланган дәреслекләрендә Р. Фәхреддин: “Яшь буынны тәрбияләү эше – ул бик мөһим социаль мәсьәлә һәм ул үзенә укучыларның вә ата-аналарның даими игътибарын таләп итә”, – дигән фикерне әйтә. Ул җаны-тәне белән чын күңелдән шуларны аңлатырга тырышып яши. Мәгърифәт һәм белем тарата: әдәби һәм био-библиографик хезмәтләрендә тормышны реалистик карашлардан чыгып бәян итә. Аңарда акыл һәм белемнең чикләнмәгән көченә ышану, үз диненне тоту, мәгърифәтне ялкынлы пропагандалау, үстерү нәтиҗәсендә үз халкын бәхетле итәргә омтылу хас.

Бу затның халык педагогикасына, яшәеш тәҗрибәсенә, ислам диненә, башка кавемнәрнең дә рухи казанышларына нигезләнгән тәрбия китаплары халкыбызны иманлы, әхлаклы итүдә инде гасыр буе дәреслек, тәрбия әсбабы, академия вазыйфасын үтәп киләләр”. Яшь буынны яхшы сыйфатлы мәдрәсәләрдә укытып һәм югары әхлак сыйфатларына ия булган мәдәниятле кешеләр итеп тәрбияләп, олы тормыш юлына әзерләүне Р.Фәхреддин, бөтен җәмгыятьнең иң изге, иң җаваплы, иң мөһим эше дип карый. Шул сәбәпле, татар җәмәгатьчелегенә бу юнәлештә дөрес һәм кирәкле эшчәнлек алып бару өчен бу китапларның әһәмияте бик зур, һәм без- укучылар өчен- чын табыш. Аның кайсы гына хезмәтен алып карасаң да, аларның һәрберсендә тәрбияле кеше башкалардан өстен куелып бирелә, чөнки һәрвакыт тәрбияле кешедән үрнәк алалар , аны мактыйлар, хөрмәт итәләр. Р.Фәхреддинның әлеге хезмәтләрендә бүгенге көнгә туры килердәй асыл үрнәкләр, күркәм нәсихәтләр, киңәшләр бик күп. “Бала ак кәгазь кебек, аңа төрле нәрсә язарга мөмкин. Шуңа күрә яхшы тәрбияне дә, яман юлга бара торган бозык тәрбияне дә кабул итәргә мөмкин”,- дип язган Р.Фәхреддин.

Р. Фәхреддиннең “Әсма”, яки Гамәл вә җәза” романында да яхшылык һәм явызлык, әдәплелек һәм әдәпсезлек, белемлелек һәм наданлык бәрелеше әдәби образларда сурәтләнә. Р. Фәхреддин, яхшылык нәтиҗәсе – бәхет, мәкер һәм явызлыкның, начар эшләрнең җәзасы – түбәнлек, хурлык, дигән идеяне персонажлар язмышында тәэсирле итеп гәүдәләндерә.

Романның үзәгендә Әсма исемле кызның  язмышы сурәтләнгән. Әтисе Габбас мулла  заманының ачык фикерле кешесе булса да, белем һәм әхлак ягыннан ул дәрәҗәдә түгел. Укымышлы, тәрбияле, акыллы  хатыны Гайшә абыстай Габбас мулланың холкын тәрбия итәргә керешә. Бергәләп төрле китаплар, рус, төрки, гарәп телләрендә төрле журналлар укыйлар.

Әсма әнә шундый тату гаиләдә әти-әнисенең үрнәгендә яхшы тәрбия ала. Тик язмыш Әсма алдына зур сынаулар куя: әтисенең хаҗга чыгып киткән җиреннән үле хәбәре килә, кайгыдан әнисе дә вафат була. Әсма кызлар белән сату итүче Зәйнүш кулына эләгә, авыр һәм куркыныч хәлләр алдында кала. Тик Әсма  тормыш төбенә тәгәрәми. Аягын сындырып, хастаханәгә эләккәч, авыручыларга китаплар укый, хатлар яза. Күркәм холыклы бу кызны  гади бер авыл хатыны үзенә тәрбиягә ала. Әсәр ахырында Әсма бәхеткә ирешә: этисе белән очраша, элек дуслашып йөргән егете белән табышып, алар бәхетле гаилә төзиләр. Гаиләдә эти-әнисеннән яхшы тәрбия алган Әсма бәхеткә ирешә.

Р. Фәхреддин: “Бала чакта алган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы үзгәртә алмас”-ди. Чыннан да, гаиләдә нигезле итеп бирелгән тәрбия кешенең гомере буена җитәрлек хәзинә ул. Шушы рухи байлыкны түкми-чәчми киләчәк буыннарга җиткерү – безнең бурычыбыз булып тора.

## III бүлек

## Кешелек сыйфатларын саклап калуда бердәнбер юл – Исламга килү

Ә нәрсә сон ул иман? Иман – Аллаһыбызның барлыгына һәм берлегенә ышану дигән сүз. Аллаһыбызны дөньяда беркем дә, беркайчан да алдый алмый, чөнки ул нәрсә булганын һәм булачагын алдан күреп, белеп тора. Шунлыктан бер үк кешедә Аллаһыбызга ышаныч та, ялган да бергә сыешып яши алмый. Киресенчә, Аллаһыбыз кешеләрне гел тугрылыкка, хак юлга керергә өндәп тора.

XX гасыр ахыры кешелеккә наркомания афәте такты. Кешелекнең тамырына балта чабыла. Ул яшьләрне үзенең “арбасына” көннән-көн күбрәк төйи бара. Наркоманнар. Алар – кешелеклелеген җуйган, иманын

саткан “тере мәет”ләр, шәүләләр. Наркомания 12-30 яшьлекләрне үзенә суырып ала.

Наркоманнар авыр хәлле гаиләдән дә, бай кеше гаиләсеннән дә чыгарга мөмкин. Ул беркемне дә аяп тормый. Берәүләр бу юлга тормыш авыр булганга, хәсрәтләрен вакытлыча онытып тору өчен бассалар, икенчеләре исә акчаларын кая куярга белмәгәнгә, эшсезлектән интеккәнгә эләгә.

Ә дөрес тәрбияне ничек алырга мөмкин соң? Ни рәвешле әти-әни баласын туры юлга бастыра ала? Үзләрен хөрмәт итәргә, картайган көннәрендә дә саклап, карап торырга ничек өйрәтергә була?

Бу сорауларның чишелешен нәкъ менә Ризаэддин Фәхреддиннең хезмәтләрендә табарга мөмкин: “Дөньяга килгән сәгать белән балалар-тәрбиягә мохтаҗлардыр. Боларны тәрбияләүчеләр дә – аналардыр. Аналар балаларның һәр эшләрен гадәткә салдылар. Тәрбияле аналар – олуглар алдында эшләргә ярамаган эшләрне балалар алдында эшләмәсләр вә сөйләргә ярамаган сүзләрне сөйләмәсләр, моннан бик сакланырлар. Шулай ук балаларның хәйләгә, ялган сөйләүләренә сәбәп булырдай нәрсәләрне кылмаслар”-,дип әйтелә “Тәрбияле ана” исемле хезмәтендә.

Ризаэддин Фәхреддин болай дип язып калдырган: “Гыйбадәтләрнең иң зурысы хәрам эшләрдән саклану вә фарызларны үтәүдән гыйбарәттер. Шуның берсе – дога кылу”.“Дога кылу (гарәпчә ялвару, үтенү) дингә ышанучы кешеләрнең Аллага сорау, үтенеч белән мөрәҗәгать итүе, яки аларга рәхмәтен белдерүе”.

Менә шушы сыйфатлардан мәхрүм ителсә, кеше имансызга, ягъни куркыныч бер затка-вәхшигә әйләнә. Моның мисалларын безгә тормышыбыз ачык күрсәтте. Бер-берсен үтерүне, көчләүне, алдауны, намуссызлыкны кешеләр бернигә дә санамый башладылар. Боларның барысы да иманны көч белән тартып алу, кешеләрне көчләп имансыз итүнең нәтиҗәсе.Табигый ки, сәламәт тән вә җан авыруларга бирешмәскә тырыша, авырса – савыгырга омтыла. Әхлакый һәм рухи авыруларга дучар

ителгән җәмгыятебез дә шулай үзен савыктыру өстендә эшләргә, начар юлда йөрмәскә тиеш.

## IV бүлек

## Дин һәм бүгенге туган телебезнең язмышы

"Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый. Боларның берсе — милли тел, икенчесе — милли кием, өченчесе — мили гореф." (Ш. Мәрҗани).

Коръәндә туган телне саклау турында аять юк-югын, тик шулай да һәр милләтнең изге бурычы — үз телен, үз динен саклау, диелә (Пәйгамбәребез с.г.в. сөннәте). Атабыз Адәмгә г.с. — беренче Пәйгамбәребезгә — Аллаһы Тәгалә бик күп телләр һәм әйберләрнең атамаларын өйрәткән. Адәм балалары ишәеп, җир йөзенә таралып, һәр кавемнең үз теле барлыкка килгән. Шулай булгач, Ш. Мәрҗани сүзләренә әйләнеп кайтып фикер йөртсәк, дин белән тел берсен-берсе саклый, аларны кискен аерырга ярамый дию түгелме соң? Язмамда  әйтәсе килгән фикеремнең берсе нәкъ шул хакта.

Мине кайбер ислам дине әһелләренең шушы мәсьәләгә берьяклы гына якын килүе, ягъни дин турында гына уйлап, телне саклау мәсьәләсен онытулары борчый. Аларның «Дин белән тел икесе ике нәрсә» дип аңлата башлаячакларын белеп, алдан ук әйтәсем килә: шулай икәнен бик яхшы беләм. Алар аерылгысыз итеп, бер-берсенә бәйләнеп куелган нәрсәләр түгел. Бер үк дин тоткан төрле милләт халыклары булуын да, бер милләт эчендә төрле дин тотучылар барын да беләм. Тик милләтне саклау — һәр мөселманның бурычы икән, телне саклауда үзеннән үзе аның бурычына әйләнә түгелме? Чөнки тел сакланмаса, милләтнең югаласы һәркемгә билгеле.

Соңгы вакытта, кемгә ярыйм диптер, мәчетләрдә русча вәгазь уку модага кереп бара. Мәдрәсәләрдә ислам кануннарын русча аңлатуның сәбәбе шул гына булуына бик ышанасы килсә дә, эш муллаларның үзләрендә дә түгел микән дигән шигем бар. Рус телле мөселманнар белән бергә рус телле муллалар күбәеп бара түгелме? Бу шигем «Безнең гәҗит»

газетасыннан (2011, № 47) Рәсим хәзрәт Хәбибулланың мәкаләсен укыгач, тагын да артты. «...Талантсыз һәм кара эш яратмаган егетләргә әле урын тагын да күбрәк: күпләре әти-әнисенең «Улым, «кара» эшне яратмыйсың, кулыңнан бернәрсә дә килми, бар, мәдрәсәдә укы, намаз укып билең сызламас, тамагың ач булмас», — киңәшләрен тотып, муллалыкка укырга баралар. Мәдрәсәдә укыганда ук, үз фикерләре булмау сәбәпле, төрле агымнарга эләгеп, хәтта әти-әниләрен кяферлектә гаепләп, халыкта ислам диненә карата тискәре караш уяталар. «Диндә милләт юк», дигән гыйбарә астында үз милләтенә нәфрәт белән карыйлар», — дип яза автор. Кискенрәк тоелса да, хаклык бардыр бу сүзләрдә. Хәзрәт башы белән белмичә сөйләмәс. Бүген татар яшьләренең күбрәк русча аралашуы беркемгә дә сер түгел. Бигрәк тә шәһәрдә үскәннәре. Мәдрәсә бетерә дә русча вәгазь сөйли. Рәхәт ич! Дин кануннары тыймаганда, нигә ата-анасы телен өйрәнеп торсын!

Иң авыр заманнарда да качып-посып намазын укыган, әби-бабасы өйрәткән доганы ничә еллар күңелендә саклап кала алган өлкән буын вәкилләренә хөрмәт йөзеннән генә дә мәчетләрдә эш татарча гына алып барылырга тиеш дип исәплим. Кайсы төбәкне алып карасаң да, ислам дине йолаларын каяндыр килгән мөселманнар түгел, шул төбәкнең үз халкы саклап калган бит.

Ш. Мәрҗани сүзләренә кире кайтып, милли кием турында фикер йөртик әле. Сүзне хөрмәтле язучыбыз Туфан ага Миңнуллинның «Иман» газетасы хезмәткәре белән әңгәмәсендә әйткән сүзләреннән (2010 ел, 7 нче сан) башлыйсым килә: «Коръән барлык кешелек өчен иңдерелгән китап, аның фарызлары үтәлергә тиеш. Ләкин диннең йолалары бар бит әле. Менә моны искә алган вакытта, аны татар үзенең тормышына җайлый. Бу бер дә Коръәнгә, аның төп догмаларына каршы килми», — ди. Җирдән сөйрәлеп баручы кап-кара хиҗаб кигән, яулыкка төренеп беткән хатын-кызлар үзләрен Гарәбстанда уңай дип табылган йоланы үтәп кенә саваплы булабыз дип өметләнәләрме? Халкыбызның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре

ислам дине кабул ителгәнче ук формалашкан һәм алар ислам кануннарына каршы килми.

Безнең әбиләребез актан киенергә яратканнар, җирдән сөйрәлгән кара кием кимәгәннәр. Хәзер дә мөселман хатын-кызлары өчен заманча тегелгән бик килешле киемнәр белән сәүдә итүче кибетләр эшли. Иң аянычлысы — яулык бәйләп, хиҗаб астына качкан кызларыбыз арасында, күп вакыт яшереп тә тормыйча, тәмәке тартып, аракы эчеп йөрүчеләрнең булуы. Монысын һич арттырмый, үз колагым белән ишеткәнне язам.

Ни кызганыч, "яулык бәйләү модасы" дигән сүзләр белән еш очрашырга туры килә хәзерге заманда. Үземә мондый "пычрак" күренеш шаһите булырга туры килгәне юк, бары тик югары уку йортында укучы авылдашым гына гаҗәпләнеп, шундый бер күренеш турында сөйләде.

- Сентябрь башында укырга килгәндә биш вакыт намазны калдырмый, яулык ябып йөри иде. Тик яулык эчендә нинди кеше яшеренгәнен бер ай тирәсе вакыт үткәч кенә абайладык. Иң элек, намазын ташлады, сәхәр ашарга дип торасы урынга, йокысын дәвам итте. Кап-кара итеп бизәнә башлады. Кашын, телен, ирен астын тиштереп, озын итеп тырнагын үстерде. Кайтышлый сыра алып эчәргә, тулай торак бүлмәсендә тәрәзәгә менеп басып, тәмәке тартырга гадәтләнеп китте. Урамда да яңа егетләр белән танышып, очрашып йөри башлады. "Сал инде бу яулыгыңны, гөнаһлы гына буласың", – дия килдек. "Юк!"– дип кыска гына җавап тотты. Әти-әниләре – дини кешеләр. Өйләренә кайтканда, тырнак киселә, алкалар салына, кап-кара итеп буялган күзләр юыла иде. Төнге уникедән дә иртәрәк кайтмаска өйрәнде. Шулай итеп, бөтенләй бозылып китте, сөйләшкәндә дә "пычрак" урам сүзләре кыстырды. Лекцияләргә дә йөрми, өй эшләрен дә хәзерләми. Кая кадәр барып җитәр иде, белмим, тик апрель аенда тулай торактан куып чыгардылар аны, – дип тезеп китте ул.

"Адәм баласы үзен-үзе тәрбияләргә һәм камилләштерергә тиеш, буй җиткән һәр кеше үзен-үзе тәрбияли ала", - дип саный ул.Моннан чыгып, бөек галим әхлакны дини-әхлак кануннарына һәм дөньяви әхлак-сагыш кагыйдәләренә бүлә. Беренчесе – мәңгелек канун, икенчесе – үзгәреп

торыр, камилләшә барыр кагыйдәләр. Минем аңлавымча, галим дин адәмне әхлакый яктан да сафландыра, әхлакый адәм җәмгыятьне яхшы якка үзгәртергә хезмәт итә. “Ислам дине  - балаларны яхшылыкка өйрәтү дине”, дип раслый ул. “Динсезлек – кешелек өчен һәлакәт ул”,- ди галим.

## Йомгак

Р. Фәхреддиннең фикерләре үз чоры укучысын гына түгел, бүгенге XXI гасыр кешесен дә кызыксындырырлык. Шулай итеп, Ризаэддин Фәхреддиннең  Ислам диненә караган кайсы гына хезмәтен алып карасаң да, һәрберсендә кешенең дөньяга карашын формалаштыруда, чын, ныклы тәрбия бирүдә, әлбәттә, гаиләнең роле зуррак булуын күрергә була.

Р.Фәхреддин халкыбызның мәдәниятен үстерүдә, милли үзлегебезне саклап калуда зур хезмәт күрсәткән бөекләребезнең берсе. Барыннан да элек аның бөек хезмәте илдә, халык белән бергә большевизамның динебезгә, милли  мәдәниятебезгә ясаган һөҗүмнәренә каршы көрәшеп, үзенең  соңгы көннәренә чаклы милләт тарафыннан тапшырылган бөек хезмәтен дәвам итүендә.

Күп акыл ияләренең акыллы, тапкыр, зирәк фикерләрен өйрәнгәннән һәм анализлаганнан соң шундый нәтиҗәгә киләсең: илдәге аяныч хәлдә яшь буында кешелек сыйфатларын саклап калуда бердәнбер юл – ул да булса рухи әхлак тәрбиясе бирү. Аны бала туганнан алып, аның гомере дәвамында алып барганда гына халык, нинди генә афәткә юлыкса да яшәвеннән туктамаячак.

Ислам диненә шикләнеп, аннан куркып караучыларга бөек галим Ризаэддин Фәхреддин  болай дип язган: “Дин кешелек җәмгыяте барлыкка килеп яши башлаганнан алып, ӘДӘП, ӘХЛАК, ШӘФКАТЬ, ИЗГЕЛЕК, ИТӘГАТЬЛЕЛЕК, КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК, НАМУС, САФЛЫК, ПАКЪЛЕК, ГАДЕЛЛЕК, ЯХШЫЛЫК һәм башка бик күп күркәм төшенчәләрне эченә алган һәм бозык эшләрдән тыелып, яхшы эшләргә генә өндәгән кануннар

тупланмасы һәм ТӘРТИП, ТӘРБИЯ һәм ӘХЛАКнең нигезе, гаиләдә тәртип сакчысы, тормышның төзек, гомернең бәрәкәтле узуына сәбәп”.

.